# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

"Татарстан Республикасында юллар фонды турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында"

"Татарстан Республикасында юллар фонды турында" Татарстан Республикасы Законына /26.12.91, № 1368-XII/ түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

4 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4 статья. Ягулык-майлау материалларын сатуга салым

Ягулык-майлау материалларын /автомобиль бензины, дизель ягулыгы, майлар, кысылган һәм сыекландырылган газ/ сатуга салымны, күрсәтелгән материалларны сатучы предприятиеләр, оешмалар һәм эшкуарлар, милек рәвешләренә, кайсы ведомствога буйсынуларына һәм оештыру-хокук рәвешләренә карамастан, сату бәясенең /акчалата хисапта/ 25 проценты күләмендә өстәлгән бәяләргә салымнан башка түлиләр.

Берләшмәләр, оешмалар , предприятиеләр һәм эшкуарлар алып саткан вакытта салым ягулык-майлау материалларын сатудан килгән табыш белән /өстәлгән бәяләргә салымнан тыш/ аларны сатып алу бәясе /өстәлгән бәяләргә салымнан тыш/ арасындагы аерма күләменнән билгеләнгән ставка буенча исәпләнелә".

5 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5 статья. Автомобиль юлларыннан файдаланучыларга салым

Автомобиль юлларыннан файдаланучыларга салымны Татарстан

Республикасы законнары буенча хокукый затлар булып саналучы предприятиеләр /Татарстан Республикасы территориясендә чит ил инвестицияләре катнашында оештырылган предприятиеләрне, эшкуарлык эшчәнлеген даими вәкилиятләр аша башкаручы халыкара берләшмәләрне һәм оешмаларны да кертеп/,эшкуарлар, чит илләрнең хокукый затлары; предприятиеләрнең мөстәкыйль нисбәте /балансы/ һәм үз исәп-хисап счеты булган филиаллары һәм башка шундый бүлекчәләре түлиләр.

Салым, билгеләнгән ставкалардан чыгып, һәр төр эшчәнлек өчен аерым-аерым исәпләнелә.

2. Автомобиль юлларыннан файдаланучыларга салым сатылган продукция,үтәлгән эшләр һәм күрсәтелгән хезмәт суммасының 0,7 проценты күләмендә салына, ә әзерләүче, сәүдә итүче /күпләп сатучы сәүдә оешмалары да керә/ һәм тәэминат - сәүдә оешмалары бу салымны әйләнешнең 0,I проценты күләмендә түлиләр.

3. Салым түләүдән түбәндәгеләр азат ителә:

колхозлар, совхозлар, крестьян /фермер/ хуҗалыклары һәм аларның берләшмәләре, авыл хуҗалыгы продукцияләрен җитештерү белән шөгыльләнүче, бу продукцияләрне сатудан килгән керемнәрнең барлык керемнәр суммасыннан 70 процент һәм аннан да күбрәк процент тәшкил итүче акционер һәм башка предприятиеләр;

тулысынча дәүләт бюджеты хисабына тотылучы учреждениеләр;

гомуми кулланылыштагы юлларны тотучы предприятиеләр.

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Бөтенроссия чукраклар җәмгыяте /БЧҖ/, Бөтенроссия сукырлар җәмгыяте /БСҖ/, Бөтенроссия гарипләр җәмгыяте /БГҖ/ нисбәтендә булган предприятиеләр;

яшелчә, җиләк-җимеш үстерү белән шөгыльләнүче бакчачылык ширкәтләре".

6 статьяда:

а/ таблицаның I пунктында еллык салым күләмен түбәндәгечә үзгәртергә:

| Салым салучы объектлар атамалары | Еллык салым күләме |
|---|---|
| Двигателенең куәте I00 ат көченә /73,55 кВтга кадәр/ кадәр булган җиңел автомобильләр, | I0 сум |
| физик затлардан | 5 сум |
| I00 ат көченнән күбрәк /73,55 кВт дан артык/ | 26 сум |
| физик затлардан | I0 сум |
| Мотоцикллар һәм мотороллерлар, | 6 сум |
| физик затлардан | 3 сум |
| Двигателенең куәте I00 ат көченә кадәр /73,55 кВтга кадәр/ булган йөк автомобильләре һәм тракторлар | 40 сум |
| I00 дән алып I50 ат көченә кадәр /73,55 кВтдан алып II0,33 кВтга кадәр/ | 80 сум |
| I50 дән алып 200 ат көченә кадәр /II0,33 кВтдан алып I47,I кВтга кадәр/ | 96 сум |
| 200 дән алып 250 ат көченә кадәр /I47,I кВтдан алып I83,9 кВтга кадәр/ | I04 сум |
| 250 ат көченнән күбрәк /I83,9 кВт дан артыграк/ | I42 сум |
| Башка үзйөрешле машиналар һәм пневмойөрешле механизмнар /ашлык җыючы һәм башка махсус авыл хуҗалыгы комбайннарыннан гайре/ | 40 сум |

б/ 4 пунктка түбәндәге эчтәлектәге икенче абзац өстәргә:

"Советлар Союзы каһарманнары, Россия Федерациясе каһарманнары, Социалистик хезмәт каһарманнары, Дан орденының өч дәрәҗәсе белән дә бүләкләнгән граждан нар, Хезмәт даны орденының өч дәрәҗәсе белән дә бүләкләнгән граждан нар";

в/ 4 пунктның 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"колхозлар, совхозлар, крестьян /фермер/ хуҗалыклары һәм аларның берләшмәләре, авыл хуҗалыгы продукцияләрен җитештерү белән шөгыльләнүче, продукцияләрне сатудан килә торган керемнәрнең гомуми күләме аларның барлык керемнәренең 70%ын һәм аннан да күбрәген тәшкил итә торган акционер һәм башка предприятиеләр";

5 пунктны төшереп калдырырга.

7 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"7 статья. Автотранспорт чараларын сатып алуга салымны автотранспорт чараларын сату - алу, алмаштыру, лизинг һәм устав фондына кертемнәр кертү рәвешендә сатып алучы предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр, эшкуарлар түли.

Салымнар автотранспорт чараларын теркәү яисә янәдән теркәү урыннарында түләнә.

2. Автотранспорт чараларын сатып алуга салым аларның сатылу бәяләреннән процентларда /өстәлгән бәягә салымны һәм акцизларны кертмичә/ түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| | |
|---|---|
| йөк автомобильләре, пикаплар һәм җиңел фургоннар, автобуслар, махсус автомобильләр һәм җиңел автомобильләр | 20 |
| тагылмалар һәм ярым-тагылмалар | 10 |

3. Автотранспорт чараларын теркәүне яисә янәдән теркәүне гамәлгә ашыручы органга автотранспорт чараларын сатып алуга булган салымның түләнүе турындагы квитанцияне яисә түләү йөкләмәсен күрсәтми торып, әлеге статьяның 2 пунктында күрсәтелгән автотранспорт чараларын теркәү яисә янәдән теркәү үткәрелми.

4. Салым түләүдән түбәндәгеләр азат ителә:

Советлар Союзы каһарманнары, Россия Федерациясе каһарманнары, Социалистик хезмәт каһарманнары, Дан орденының өч дәрәҗәсе белән дә бүләкләнгән гражданнар, Хезмәт даны орденының өч дәрәҗәсе белән дә бүләкләнгән гражданнар;

Чернобыль афәте аркасында радиациягә дучар ителгән гражданнар категорияләре, 1991 елның 12 маендагы "Чернобыль афәте аркасында зыян күргән гражданнарны җәмгыяви яклау турындагы" СССР Законы нигезендә;

мотоколяскалар һәм автомобильләр сатып алучы гарипләрнең барлык категорияләре;

устав эшчәнлекләрен үтәү өчен сатып алынган транспорттан файдаланучы гарипләрнең җәмәгать оешмалары;

шәхси кулланылышка җиңел автомобильләр сатып алучы гражданнар;

пассажирлар йөртүче автотранспорт чараларының /таксидан гайре/ гомуми кулланылыштагы автотранспорт предприятиеләре;

колхозлар, совхозлар, крестьян /фермер/ хуҗалыклары һәм аларның берләшмәләре, авыл хуҗалыгы продукцияләрен җитештерү белән шөгыльләнүче, продукцияләрне сатудан килә торган керемнәрнең гомуми күләме аларның барлык керемнәренең 70%ын һәм аннан да күбрәген тәшкил итә торган акционер һәм башка предприятиеләр, авыл хуҗалыгына хезмәт күрсәтүче предприятиеләр һәм оешмалар: "Татсельхозтехника", "Татсельхозхимия", "Татагропромэнерго" берләшмәләре;

гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын тотучы предприятиеләр;

хуҗалык исәбендәге төзелмәләрдән гайре, бюджет оешмалары

һәм учреждениеләре;

Йола хезмәте күрсәтүче, бу хезмәтләрне гамәлгә ашырудан килә торган керемнәренең гомуми күләме аларның барлык керемнәренең кимендә 80 процентын тәшкил итә торган предприятиеләр;

автотранспорт чараларын аукционда сатып алган хокукый затлар һәм гражданнар. Күрсәтелгән автотранспорт чараларын сатып алуга салым суммасы аларның сатылу бәясе суммасының 20 проценты күләмендә аукционны оештыручылар тарафыннан түләнә һәм юл фондына җибәрелә".

Законга II статья өстәргә:

"II статья. Салымнар түләүдән азат итү һәм аларның күләмнәрен киметү буенча вәкаләтләр

Гражданнарның, предприятиеләрнең, оешмаларның һәм учреждениеләрнең аерым категорияләрен салым түләүдән тулысынча азат итү яисә аларның күләмнәрен киметү Татарстан Республикасы Югары Советы тарафыннан гамәлгә ашырыла".

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1993 елның 5 марты
№ I770-XП